**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Фатих Хөснинең «Чыбыркы» хикәясе**

**1. Фатих Хөснинең яшәгән елларын билгеләгез.**

а) 1910—1989 нчы еллар;

ә) 1908—1996 нчы еллар;

б) 1928—2001 нче еллар.

**2. Ул кайда туган?**

а) Теләче районы Олы Мәтәскә авылында;

ә) Әлки районы Мәүләшә авылында;

б) Баулы районы Кызылъяр авылында.

**3. Аның нинди дәүләт бүләкләре бар?**

а) «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исеме;

ә) Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе;

б) Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, «Татарстанның халык язучысы» дигән мактаулы исеме.

**4. «Чыбыркы» хикәясендә вакыйга кем авызыннан сөйләнә?**

а) Рәшит;

ә) Рәшитнең этисе;

б) Рәшитнең әнисе.

**5. Кем ул Рәшит?**

а) беренче сыйныфта укучы малай;

ә) икенче сыйныфта укучы малай;

б) өченче сыйныфта укучы малай.

**6. «Әнисе ноталар сумкасын утынлыктан табып алып керде» дигән җөмлә Рәшитнең нинди сыйфатын күрсәтә?**

а) музыканы яратмавын;

ә) тәртипсез малай булуын;

б) музыка мәктәбенә йөрергә теләмәвен.

**7. Җәй буе авылда торып килгән малайның кайсы сыйфаты этисе өчен иң яхшысы?**

а) үскән, чәчләре җиткән, кап-кара булып каралган;

ә) бер генә ботинка да туздырмаган, үскән, кап-кара булып каралган;

б) аяклары чебиләп беткән.

**8. Рәшит чемоданыннан нәрсә чыгара?**

а) күчтәнәч;

ә) киемнәрен;

б) чыбыркы.

**9. Рәшит нинди көтү көткән?**

а) сарык көтүе;

ә) сыер көтүе;

б) тай көтүе.

**10. Чыбыркының төп вазифасы нинди?**

а) көтү көтәргә кирәк;

ә) уйнар өчен кирәк;

б) чыбыркы – ул реликвия.

**11. Чыбыркының шәплеге кайсы җөмләдә аермачык күренә?**

а) Элек – сабы, аннары сап төбендәге дегетләп катырылган төене чыкты, аннары беләк юанлыгы чыбыркысы чыга башлады.

ә) Чыга бара, чыккан саен нечкәрә бара чыбыркы.

б) Малайны әйтәм, кайдан кулга төшергәндер бу шәп әйберне, шундый озын, шундый озын, сузсаң, ачуым килмәгәе, Казаннан Мәскәүгә җитә.

**12. Рәшитнең «корольгә» әйләнүенең сәбәбе нәрсәдә?**

а) малайлар күп, ә чыбыркы бер генә;

ә) иртәдән кичкә кадәр ишегалдында чыбыркы шартлаткан тавыш ишетелеп тора;

б) чыбыркы аркасында еш тавыш чыга.

**13. Җәнҗал нәрсәдән чыккан?**

а) Рәшит чыбыркысын шартлатып карарга бер малайга да бирмәгән;

ә) чыбыркының ак кыллы очы ялгыш кына икенче берсенең күзенә барып кергән;

б) «Чыбыркы кемнеке?» дигән сорау купкан берзаман.

**14. Әтисенең малае белән горурлануы кайсы юллардан күренә?**

а) Ә ул, үзенең әлеге шул данлыклы чыбыркысы белән почмактагы су торбасына бәйләнеп куелган килеш, еламыйча да, көлмичә дә басып тик тора.

ә) Әнисе биргән җәзадан мин аны, әлбәттә, коткармадым.

б) Үз чыбыркысы белән торбага бәйләнеп куелган килеш, беребезгә дә ялынмыйча басып торучы ул малай минем өчен дөньядагы бөтен нәрсәдән дә газизрәк иде.

## Ачкыч

1. Ә
2. А
3. Б
4. Ә
5. Ә
6. Б
7. Ә
8. Б
9. Б
10. А
11. Б
12. А
13. Б
14. Б

# Бәяләү

**13-14 балл – “5”ле**

**11-12 балл – “4”ле**

**7-10 балл – “3”ле**